ҖОМГА
26
ФЕВРАЛЬ
1943 ел.
№ 47 (6769)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

# КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

## ФРОНТОВИК СЕМЬЯЛАРЫНА ЯРДӘМНЕ ТАГЫН ДА КӨЧӘЙТИК

Бу тарихи көннәрдә тылның фронтка ярдәме күп тапкырларга артты. Совет патриотлары Кызыл Армия өчен үзләренең саклык средстволарыннан танклар колонналары, самолетлар эскадрильялары төзиләр. Фронтка күп санда җылы киемнәр һәм ашамлык продуктлары җибәрәләр. Алар промышленностьта һәм авыл хуҗалыгында фронт өчен кирәк булган барлык төр продукцияне планга караганда арттырып җитештерү өчен үз-үзләрен аямыйча көрәшәләр. Фронтовик семьялары турында кайгыртучанлык күрсәтү һәм аларга һәрьяклап ярдәм итү эше дә фронтка күрсәтелә торган бу ярдәмнәрнең аерылгысыз тармагы булып тора.

Бездә сугышчы һәм аның семьясы барлык совет халкының кайнар мәхәббәте һәм кайгыртучанлыгы белән чолганып алынган. Совет сугышчысы үзенең тылда калган семьясының, туганнарының һәм якыннарының кирәк вакытта реаль ярдәм ала алачакларына нык ышана.

Күптән түгел матбугатта Иваново өлкәсе хезмәт ияләренең иптәш Сталинга язган хатлары басылды. Алар үзләренең бу хатларында Иваново өлкәсендәге совет, партия һәм профсоюз оешмаларының Кызыл Армия командирлары һәм сугышчыларының семьяларына күрсәткән бик зур ярдәмнәре турында сөйлиләр.

Хәзерге вакытта бөтен халык хәрәкәтенә әверелеп киткән бу мактаулы башлангычка безнең республикабызның да совет, партия һәм профсоюз оешмалары кушылдылар. Соңгы көннәрдә генә дә бик күп кенә фронтовик хатыннарына, балаларына өс киемнәре һәм аяк киемнәре алып бирелде. Йөзләрчә кубометр утын китертелде һәм башка төрле ярдәмнәр күрсәтелде.

Партбюро секретаре урынбасары иптәш Закиров булган Н-че завод җитәкчеләре бу эшкә аеруча зур әһәмият бирәләр. Заводның профсоюз оешмасы узган бер ел эчендә генә дә кызылармеец семьяларына 48.000 сум күләмендә кайтарылмый торган ссуда бирде. Заводта фронтовикларның мәктәп яшендәге балалары өчен 350 кешелек ашханә эшләп килә. 1943 нче елга чыккач кына да кызылармеец семьяларына 100 йөк утын китерделәр.

Республикабызның күп кенә районнарында кызылармеец семьяларына ярдәм итү эше игътибар үзәгенә куелган. Заинский районы, Түбән Пәнәче авылы гражданы—фронтовик иптәш Ш. Юсупов үзенең редакциягә язган хатында болай ди:

— Үзем фронтка киткәндә минем семьямда алты кеше калды. Фронтта вакытта мин колхоз правлениесенең һәм район оешмаларының һәрвакыт ярдәм итеп торулары турында семьямдан күңелле хатлар алып тордым. Хәзер мин авылга ялга кайттым һәм бу ярдәмне үз күзем белән күрдем. Минем семья һәрьяктан җитеш тора. Тиешле булган паекны һәм пособияне вакытында алып бара. Кышка җитәрлек утын белән тәэмин ителгән. Мондый кайгыртучанлык өчен безнең партиябезгә, хөкүмәтебезгә бик зур рәхмәт.

Фронтовик семьяларына карата шундый кайгыртучанлыкны һәм ярдәмне бөтен җирдә: һәрбер районда, һәрбер оешмада булдырырга мөмкин. Кызганычка каршы, бу эшнең политик әһәмиятен аңлап җиткермәүче, фронтовик семьяларының сорауларына формаль һәм бюрократларча караучы җитәкчеләр дә бар әле.

Сталин район советының социаль тәэминат бүлеге работниклары кызылармеец семьяларының гаризаларына, жалобаларына җансыз карағаннар. Аларны вакытында тикшермәгәннәр. Район советы башкарма комитеты председателе Панников моның өчен каты җавапка тартылды. ВКП(б) ның шәһәр комитеты бюросы аны эшеннән алды һәм партия сафларыннан чыгарды. Фронтовик семьяларына бюрократларча җансыз караш фактларына һичбер төрле урын булмаска тиеш.

Совет, партия, профсоюз оешмалары социаль тәэминат учреждениеләренең эшен нык контроль астына алырга һәм андагы җитешсезлекләрне үз вакытында ачып салырга һәм фронтовик семьяларына ярдәмне тагын да яхшырту өчен барлык чараларны күрергә тиешләр.

# Совет Информбюросыннан

## 25 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

25 нче февральгә каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак безнең подразделениеләр төнлә белән бер биеклеккә барып чыктылар һәм каты штык бәрелеше нәтиҗәсендә аны алдылар. Бу сугышта 100 гә якын гитлерчы юк ителде. Мылтык уты белән дошманның бер самолеты атып төшерелде.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган ике пунктны алдылар. Н-че часть сугышчылары немецлар пехотасының контратакасын кире кайтардылар. Берничә йөз гитлерчы юк ителде, дошманның 5 танкысы зарарланды һәм яндырылды. Икенче бер участокта совет танкистлары немецларның фронт линиясенә бара торган обозын тар-мар иттеләр. Сугыш припаслары төялгән 18 автомашина һәм 23 повозка юк ителде.

* * *

Краматорскаядан көньяк - көнбатыштарак безнең гаскәрләр дошман танкларының һәм пехотасының контратакаларын кире кайтардылар. Н-че часть участогында танкка каршы артиллерия һәм бронебойщиклар уты белән немецларның 6 танкысы, 2 бронемашинасы һәм 16 автомашинасы юк ителде. Бер батальон дошман пехотасы таркатылды һәм бер өлеше кырып бетерелде.

* * *

Харьковтан көнбатыштарак безнең гаскәрләр алга бардылар. Н-че часть подразделениеләре дошманның алгы заслоннарын тар-мар иттеләр һәм халык яши торган бер пунктны алдылар. Урам сугышында 200 дән артык немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Курскидан төньяктарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Малоархангельск районында 14 орудие, берничә йөз винтовка, 50 меңгә якын патрон, йөк төялгән 52 автомашина һәм 162 повозка, ашлык һәм бәрәңге складлары кулга төшерелде. Икенче бер участокта Н-че часть сугышларның ике көне эчендә 300 гә якын немец солдатларын һәм офицерларын юк итте. Дошманның 56 солдаты плен алынды.

* * *

Краснодардан көнбатыштарак Н-че берләшмә частьлары өч көн эчендә бер батальоннан артык немец солдатларын һәм офицерларын кырдылар. 15 орудие, 67 пулемет, 124 автомашина, 167 ат, 2.500 снаряд, 2.000 мина, бер сугыш припаслары склады, төрле сугыш милекләре һәм азык төялгән 6 склад кулга төшерелде. Дошманның 164 солдаты һәм офицеры плен алынды.

* * *

Смоленск өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче отрядның партизаннары 12 нче январьдан 5 нче февральгә кадәр булган вакыт эчендә немецларның 6 хәрби эшелонын һәлак итүне оештырганнар. 110 вагон, платформа һәм цистерналар җимерелгән һәм зарарланган. Җимерек вагоннар астында калып дошманның бик күп солдатлары һәм офицерлары һәлак булган.

* * *

Кызыл Армия сугышчылары, командирлары һәм политработниклары Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның приказын гаять зур рухлану белән каршы алдылар. Фронт буендагы һәм тылдагы күп гарнизоннарда приказ укылганнан соң массовый митинглар булып үтте. Шулай ук фронтның күп кенә участокларындагы позицияләрдә дә кыска гына митинглар булып алды. Кызыл Армия сугышчылары, командирлары һәм политработниклары үзләренең тәэсирле речьләрендә дошманга каршы ударларны көчәйтергә һәм аны тәмам кыйнап бетерергә нык карар биргәнлекләрен белдерәләр.

Воронеж фронтында командиры өлкән лейтенант иптәш Деев булган подразделениедә, кызылармеец иптәш Сөләйманов ялкынлы речь белән чыкты. Ул болай диде: «Немец-фашист кол итүчеләр изүе астында газаплanучы миллионнарча совет кешеләре безне көтәләр. Гитлерчыларны тәмам тар-мар итеп һәм юк итеп бетергәнчегә кадәр аларны рәхимсезлек белән кыйныйк һәм куыйк».

Көньяк-Көнбатыш фронтта, командиры иптәш Журавлев булган гвардия частенда сержант иптәш Жеслин митингта речь белән чыкты. Иптәш Жеслин болай диде: «Ватаныбыз безгә яхшы һәм мактаулы бурыч йөкләде. Ул—безгә совет җирен немец-фашист кеше ашаучылардан чистарту бурычы. Шулай булгач,иптәшләр, бүген, Кызыл Армиянең 25 еллыгы көнендә, сугышчан гвардия байрагын хурлыкка калдырмабыз дип, Верховный Баш Командующий приказын намус белән үтәрбез дип һәм совет халкының ышанычын акларбыз дип ант итик. Немец-басып алучыларга көндез дә, төнлә дә тынычлык бирмичә, аларны тагын да ныграк энергия белән кыйныйк».

Иптәш Сталин приказы укылып чыкканнан соң командиры иптәш Кондратюк булган частьның бер группа очучылары хәрби заданиене үтәү өчен очып киттеләр. Гвардия капитаны иптәш Кисляков командалыгындагы 8 совет истребителе 23 нче февральдә немецларның 7 самолетын бәреп төшерделәр.

Карелия фронтында командиры иптәш Перепелица булган частьта митингта снайпер кызылармеец иптәш Остриков чыгып сөйләде. Ул болай диде: «Мин инде 96 фашистны кырдым. Иптәш Сталинга һәм Ватаныбызга ант итәм: көчемне дә, тормышымны да кызганмам һәм фашист кабахәтләрне көндез дә, төнлә дә бертуктаусыз юк итәрмен».

Москва хәрби округы частьларында митинглар зур күтәренкелек белән үтте. Н-че полкта старшина иптәш Чурилов речь сөйләде. Ул болай диде: «Иптәш Сталин приказы безгә дошманны җиңүгә бару юлын күрсәтте. Бер генә минутны да бушка үткәрмичә, сугыш эшен өйрәнүебезне яхшыртыйк һәм коралыбызның тиңдәшсез мастерлары булыйк. Верховный Баш Командующий безне сугышка җибәргәч, без үз ватаннарының намусы, азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен сугышучы совет сугышчыларының нәрсәгә сәләтле икәнлекләрен күрсәтербез».

# ВЕРХОВНЫЙ БАШ КОМАНДУЮЩИЙНЫҢ ПРИКАЗЫ ХЕЗМӘТТӘ ЯҢА ҖИҢҮЛӘРГӘ РУХЛАНДЫРА

## Сталинчы вахтага бастылар

Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә багышланган ярышка кушылып алган йөкләмәләрен завком председателе урынбасары иптәш Кисарина булган завод коллективы намус белән үтәп чыкты. Шушы көннәрдә генә ВЦСПС тан һәм Наркоматтан шатлыклы телеграмма килде: завод, январь аенда производство программаларын 141,6 процентка үтәве белән, Бөтенсоюз социалистик ярышта икенче урынны алды. Февраль ае планы да, һичшиксез, күп арттырып үтәләчәк. Бөек полководецыбыз, Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның 23 нче февраль приказы уңае белән цехларда үткәрелгән митинглар һәм андагы ялкынлы чыгышлар моңа тулысынча ышаныч бирәләр.

Начальнигы иптәш Аполонников булган цех, айлык планны 142,1 процентка үтәп, ярышта завод күләмендә беренче урынга чыкты һәм аңа заводның күчмә Кызыл Байрагы тапшырылды. Иптәш Сталинның приказына багышланган митинг бу цехта аеруча зур күтәренкелек белән үтте.

—Безне җиңүләрдән җиңүләргә алып баручы бөек полководецыбыз иптәш Сталинның приказы фронтта да, тылда да бер тигез тирән шатлык тудырды,—ди цех начальнигы иптәш Аполонников.—Фронттагы уңышлар безне шатландырган кебек, безнең уңышларыбыз да фронтовикларны шулай ук көчле шатландыра. Һөҗүм итеп баручы героик Кызыл Армиягә булышлыгыбызны тагын да көчәйтик, фронтка продукцияне тагын да күбрәк бирик!

Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның даһи җитәкчелеге нәтиҗәсендә Кызыл Армиянең зур уңышларга ирешүе һәркайда да хезмәт энтузиазмын бик күп тапкыр көчәйтә. Коллективлар үз өсләренә яңа йөкләмәләр алалар һәм фронт өчен, дошманны тар-мар итү өчен тагын да күбрәк арттырылган энергия белән эшләргә сүз бирәләр.

Завод коллективы, Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның приказына җавап итеп, 24 нче февральдән башлап Сталинчы вахтага басып эшли башлады.

## Тагын да яхшырак эшләү өчен

Казандагы скорняк тегү фабрикасы цехларында иптәш Сталинның тарихи приказына багышланган митинглар зур күтәренкелек белән үтәләр.

— Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә алган йөкләмәләребезне без намус белән үтәп чыктык,—ди партоешма секретаре иптәш Никитин.—Фабрика ике айлык планны 23 нче февральдә үтәргә, хезмәт җитештерүчәнлеген 15 процентка күтәрергә йөкләмә алган иде. Бүген, иптәш Сталинның приказын өйрәнгәндә, Кызыл Армиягә, Верховный Баш Командующий иптәш Сталинга рапорт бирә алабыз: ике айлык план 23 нче феварльгә 100,7 процент итеп үтәлде. Хезмәт җитештерүчәнлеге 24 процентка артты. Бөек полководецыбыз иптәш Сталинның приказына җавап итеп без үз күрсәткечләребезне алда тагын да күтәрербез.

Митингта массовый цех начальнигы иптәш Праги чыгыш ясап, иптәш Сталинның приказына җавап буларак май алды ярышын җәеп җибәрергә чакырды. Бу чакыру барлык коллектив тарафыннан алкышлап каршы алынды.

Юлбашчыбызның тарихи приказы фабрика эшчеләрен, инженер-техник работникларын һәм хезмәткәрләрен хезмәт фронтында тагын да зуррак җиңүләргә рухландыра. Алар, приказга җавап итеп, Май алды ярышына кушылалар һәм үз өсләренә яңа йөкләмәләр алалар.

РӘСЕМДӘ: беренче номерлы тегү фабрикасы стахановчысы Е. П. Ермолаева. Ул Кызыл Армиянең 25 еллыгына алган йөкләмәсен 126 процент үтәде.

С. Парфенов фотосы.

# БӨЕК БУЛӘК

Әнисе белән шәһәргә килгәндә Камалетдинга 3 яшь иде. Әнисе фабрикага эшкә керде, ә ул барлык вакытын күршеләрдә торып, урамда йөреп үткәрде. 12 яшендә инде Камалетдин үзе фабрикада эшли башлады. 14 яше тулганда әнисе үлеп, үзенә-үзе хуҗа булып калды. Аңа төрле хәлләрне күрергә, мастерларның кычкыруларын ишетергә, кайбер вакытларда кыен да алырга туры килде.

1911 нче елда 24 яшьлек егет Камалетдин Бәдретдинов заводка эшкә керде. Хезмәт сөючәнлек сыйфаты анда бала вакыттан ук тәрбияләнгән иде. Заводка керү белән аны иң авыр эшкә җибәрделәр, ул курыкмыйча риза булды.

Заводта берсе - берсенә ошаган көннәр бик авыр үттеләр, Камалетдин сменага бөтен кешедән алда килде, һәр эшкә игътибар белән тотынды, кешеләрне, агрегатларны, заводны өйрәнде. Эшчеләр һәм мастерлар бу тыныч күңелле, тыйнак, тыңлаучан кешене яраттылар. Мастерлар аңа нинди задание бирсәң дә үти торган кеше дип карадылар.

* * *

Еллар үтте. Бөек Октябрь Социалистик Революциясе Бәдретдиновның производствочы булып үсүе өчен киң юл ачты.

Тора-бара Камалетдин эшче, аппаратчы, бригадир булып китте. Аның күз алдында производство яхшырганнан-яхшыра барды, үзенең цехы, бөтен завод үсте һәм киңәйде.

Хәзер иптәш Бәдретдиновка 55 яшь. Ул цехта 30 елдан артык эшләде. Соңгы елларда Камалетдин пенсиягә чыгарга вакыт түгел микән, картлык көнемдә ял итеп алсам ничек булыр икән, дип уйлана башлады. Ләкин заводтан башка яшәүне күз алдына китерә алмады ул. Андый тормыш буш, кирәксез кебек тоелды. Сугыш башлангач Камалетдин ял турындагы уйларын бөтенләй башыннан чыгарып ташлады. Сугыш шартлары производствода эшне катлауландырды, җаваплылык артты, таләпчәнлек күтәрелде. Ләкин карт Камалетдин кыенлыклардан курыкмады.

Ул үз эшенә тагын да игътибарлырак карап, төгәл һәм пөхтә эшли башлады. Карт үзенең көчен кызганмыйча, вакыты белән исәпләшмичә эшләде. Ул бер төрле бүләк турында да уйламаган иде, ә аны иң югары бүләк белән бүләкләделәр.

Бер көнне Камалетдин эш көнен планлаштыру турында уйлый-уйлый сменага барганда, юлда аны смена начальнигы инженер Мусатов куып җитте һәм шатланып:

— Иптәш Бәдретдинов, бөек бүләк белән котлыйм. Намуслы хезмәтең өчен Совет хөкүмәте сине Ленин ордены белән бүләкләде,—диде.

Камалетдин ышанмады. Ни өчен бүләкләделәр? Дөрес, ул күп эшләде, һәрвакыт тырышып эшләде. Башкача мөмкин түгел. Бөтен кеше шулай эшләргә тиеш!

Сменадан соң картны митингка чакырдылар. Заводның бер төркем эшчеләрен орденнар һәм медальләр белән бүләкләү турында СССР Верховный Советы Президиумының Указы укылды. Исемлектә беренче аның фамилиясе иде. Бергә эшләгән иптәшләр, цех һәм завод җитәкчеләре аны җылы рәвештә котладылар, аңа яңа көч һәм сәламәтлек теләделәр. Карт тирәнтен дулкынланды. Ул яшьле күзләрен сөртә-сөртә берничә сүз белән генә киләчәктә тагын да яхшырак эшләячәге турында белдерде.

Бригадир Бәдретдинов әлектәгечә үзенең цехында эшли. Тиздән аның бу цехта эшли башлавына 33 ел тула.

— Хәзер мин үземне ике тапкырга яшәргән кебек хис итәм,—ди ул.— Мин бер генә нәрсә телим—эшләргә һәм эшләргә, бөтен көчемне, бөтен тәҗрибәмне ватаныма, халкыма, дошманны җиңү эшенә бирергә! Мин үземне бик көчле хис итәм. Мин бу көчне менә моннан алам.

Һәм Камалетдин Ленин ордены тагылган урынга — йөрәгенә күрсәтә.

**Б. ОРЕШНИКОВ.**

КОМСОМОЛ ТОРМЫШЫ

# БӨЕК ИСЕМНЕ АКЛАУ ӨЧЕН

Н-че заводның алдынгы эшче яшьләре Ленин—Сталин комсомолы сафларына керергә һәм бу бөек исемне намуслы эшләре белән акларга омтылалар.

Күптән түгел генә яшь эшче фрезеровщица Цирулис комсомол сафларына алынды. Шуннан соң ул, производствода бөтен көчен, бөтен энергиясен биреп эшли башлады, гүзәл күрсәткечләр бирде.

— Мин хәзер комсомолка: Бу исем миңа гаять зур бурычлар йөкли. Ул бурычларны үтәү йөзеннән мин үземнең станогымны фронт станогы дип атыйм һәм нинди генә задание бирсәләр дә төгәл итеп үтәрмен,—дип белдерде ул.

Чыннан да шулай булды.

Начальнигы иптәш Волков булган цехка барып керү белән, башында кечкенә генә флаг эленгән станок күзгә бәрелә. Бу станокта иптәш Цирулис һәркөнне заданиене 150—160 процентка үтәп бара.

Алдынгы токарь Баландин иптәш тә комсомол сафларына кабул ителде. Аның үрнәкле эше күпләргә билгеле. Ул һәрвакыт планны 250—270 процентка үти. Гольштейн иптәш тә, ВЛКСМ сафларына кабул ителгәннән соң, ике токарный станокта бер юлы эшли башлады һәм икешәр норма бирүгә иреште.

Яшь эшче Балакирев башта мактарлык эшләми иде. Аның тарафыннан дисциплинаны бозу кебек фактлар да булгалады. Бу турыда цехның комсомол оештыручысы иптәш Доргин аның белән берничә тапкыр беседалар үткәрде.

— Мин иптәш Балакиревка нинди генә задание бирсәм дә, аны срогыннан алда һәм яхшы сыйфатлы итеп үти,—дип мактый аны хәзер мастер Осокин.

Шулай итеп, безнең заводта комсомол сафына кабул ителгән алдынгы яшьләр производство эшендә дә, җәмәгать тормышында да актив катнашалар. Ленин—Сталин комсомолы дигән бөек исемне намус беләнаклыйлар.

**А. КУЗНЕЦОВ.**

# ЯШЬЛӘРНЕҢ АКТИВЛЫГЫ ҮСӘ

Иптәш Калинин, алдынгы комсомол оешмалары секретарьлары киңәшмәсендәге чыгышында, комсомолецлар алдына гаять җаваплы бурычлар куйды. Ул, комсомолецларны промышленностьта, транспортта һәм авыл хуҗалыгында тагын да яхшырак эшләргә, фронт таләпләрен яхшы итеп үтәргә чакырды. Шулай ук, алдынгы яшьләр хисабына комсомол сафларын бертуктаусыз үстерә бару мәсьәләсе белән җитди шөгыльләнергә кирәклекне күрсәтте.

Безнең Ютазы район яшьләре арасында иптәш Калининның бу чыгышын тирәнтен өйрәнү эше оештырылды. ВЛКСМ ның район комитеты пленумы членнары һәм башлангыч комсомол оешмаларының секретарьлары өчен район үзәгендә семинар оештырылды. Урыннарда комсомол җыелышларында докладлар куелды һәм беседалар үткәрелде. Иптәш Калинин чыгышын өйрәнгәннән соң комсомолецларның һәм яшьләрнең политик һәм производство активлыклары тагын да күтәрелде. Комсомол оешмаларында эш сизелерлек яхшырды. Алдынгы яшьләр хисабына комсомол сафлары шактый үсте. Иптәш Калинин чыгышын өйрәнгәннән соң, районда комсомол сафларына кабул ителүчеләр саны 213 кешегә җитте.

«Тарлау», «Баланлы» колхозларында яңа оешмалар төзелде.

«Игенче № 2», «Хөррият» колхозлары янындагы комсомол оешмалары соңгы вакытта аеруча яхшы эшли башладылар. Бу колхозларда партия оешмалары булмаганлыктан, колхоз производствосына турыдан-туры комсомол оешмалары җитәкчелек итәләр. Бу колхозлар кыр эшләрен һәм дәүләт алдындагы йөкләмәләрне срогында үтәделәр.

Хәзер күп кенә комсомолецлар ферма мөдирләре, кырчылык бригадирлары постына күтәрелделәр. 22 кеше тракторчылар әзерләү, 5 кеше комбайнчылар, 5 кеше колхоз хисапчылары курсларында укыйлар.

Ләкин шуны әйтергә кирәк: районда начар эшләүче оешмалар да бар әле. Ленин һәм Маркс исемендәге колхозлар янындагы комсомол оешмалары әнә шундыйлар рәтенә керәләр. Бу оешмаларның секретарьлары үз эшләренә җавапсыз карыйлар һәм эшлексезлек күрсәтәләр. Бу оешмаларның эшләрен яхшырту өчен конкрет чаралар күрергә кирәк.

Комсомолецлар һәм союздан тыш яшьләр арасында политик - тәрбия эшләрен тагын да көчәйтү буенча да күп эшлисе бар әле.

**Ф. ВАХИТОВА.**

# КОЧЕГАР ГРУНИННЫҢ ЯХШЫ ИНИЦИАТИВАСЫ

Казан тимер юлы деполарыннан берсендә паровоз кочегары иптәш Грунин, утын якканда казанда югары кызулык тәэмин итү өчен, утын запасын тендерда сайлау практикасын кертте. Грунин юан һәм нечкә, юеш һәм коры утынnarны аерып куя. Соңыннан аларны юлның профиленә карап, казанда парның нормаль күләмдә булуын тәэмин итәрлек итеп яга.

Бу кыйммәтле инициатива паровоз бригадасына поездларны Кривонос темпы белән йөртергә, ягулыкка шактый экономия ясарга мөмкинлек бирә.

* * *

Әгерҗедәге боз пункты, Кызыл Армиянең XXV еллыгы хөрмәтенә, боз әзерләү планын вакытыннан элек үтәп чыкты. 6 мең кубометрдан артык боз әзерләнде.

# МОСКВАНЫҢ ПАРТИЯ ҺӘМ СОВЕТ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ ҺӘМ ХӘРБИ ДИҢГЕЗ ФЛОТЫНЫҢ 25 ЕЛЛЫГЫНА БАГЫШЛАНГАН ҖЫЕЛЫШЫ

22 нче февральдә, Союзлар йортының Колонналы залында, Москваның җәмәгать һәм партия оешмаларының Кызыл Армиянең һәм Хәрби-Диңгез Флотының 25 еллыгына багышланган җыелышы булды. Җыелышта катнашучылар арасында— СССР Верховный Советы һәм РСФСР Верховный Советы депутатлары, партия работниклары, Москва предприятиеләренең җитәкчеләре һәм стахановчылары, Кызыл Армия һәм Хәрби-Диңгез Флоты частьларының вәкилләре.

Җыелышның президиумында — ВКП(б) ның Москва комитеты һәм Москва шәһәр комитеты секретаре иптәш А. С. Щербаков, Советлар Союзы Маршалы иптәш Буденный, СССР ның Хәрби-Диңгез Флоты Наркомы адмирал Кузнецов, ВЦСПС секретаре иптәш Николаева һәм башкалар.

Җыелышны ВКП(б) ның Москва шәһәр комитеты секретаре иптәш Г. М. Попов ача.

Почетлы президиумга Сталин, Молотов, Калинин, Ворошилов, Андреев, Микоян, Каганович, Жданов, Хрущев, Берия, Шверник, Маленков, Щербаков һәм Вознесенский иптәшләрне сайлау турындагы тәкъдим көчле кул чабулар белән каршы алына.

Кызыл Армиянең 25 еллыгы турында доклад ясау өчен ВКП(б) Үзәк Комитеты члены иптәш Е. Ярославскийга сүз бирелә.

Иптәш Ярославский үзенең докладын героик Кызыл Армия һәм Хәрби-Диңгез Флоты хөрмәтенә, большевиклар партиясе һәм Верховный Баш Командующий иптәш Сталин хөрмәтенә котлау сүзләре белән тәмамлый.

Дәүләт Оборона Комитеты Председателе Верховный Баш Командующий иптәш Сталинга котлау җибәрү турындагы тәкъдимне җыелышта катнашучылар гаять зур рухлану белән каршы алалар. Барысы да урыннарыннан торалар. Кул чабулар берничә минутлар буена өзлексез дәвам итә.

— Яшәсен Кызыл Армиянең бөек полководецы иптәш Сталин! Яшәсен данлыклы Кызыл Армия!—дигән тавышлар яңгырый.

Җыелыштан соң башкаланың иң яхшы артистлары катнашы белән зур концерт бирелде. (ТАСС).

# ФРОНТ ҺӘМ КОЛХОЗ

## *КЫЗЫЛ АРМИЯБЕЗНЕҢ ФРОНТТАГЫ УҢЫШЛАРЫ ТЫЛДА ТАГЫН ДА ЯХШЫРАК ЭШЛӘРГӘ РУХЛАНДЫРА*

**Бөек Ватан данлыклы Кызыл Армиянең 25 еллыгын каршылады. Бу бөек дата батыр Кызыл Армиянең героик тарихына гүзәл бер сәхифә булып керәчәк. Чөнки ул илебезнең барлык хезмәт ияләре өчен, бөтен дөньядагы азатлык сөюче халыклар өчен зур шатлык алып килә. Бу шатлыклы бәйрәм алдыннан һәрбер көн, һәрбер сәгать искиткеч гүзәл җиңүләр белән бизәлә.**

**Сталинград һәм Ленинград геройларының, Курскийны, Ростовны, Харьковны азат иткән батыр сугышчыларның уңышлары республикабызның колхозчыларын намус хезмәткә тагын да ныграк туплады. Колхоз авылының яше-карты язгы чәчүне большевикларча эшләп каршылый. 1943 нче елның язын тылда—хезмәт фронтында да җиңү язы итү өчен көрәшә. Тылдагы халык үзенең фронттагы куркусыз улларыннан, кыю кызларыннан калышмаска тырыша.**

**Газетабызның бу битендә Арча районының «Орнашбаш» колхозы патриотлары менә шушы турыда сөйлиләр. Алар героик Кызыл Армиянең 25 еллыгын эш белән каршылаулары, фронтовиклар белән бер сафта атлаулары турында белдерәләр.**

## Ил батырларына

— Менә Ростов шәһәре, әнә Ворошиловград.

— Харьков тагын безнеке!

Колхоз правлениесе бинасының стенасына эленгән карта янында һәркөнне, иртәнге сәгатьләрдә кеше өзелми. Анда зур-зур шәһәрләрнең дошманнан чистартылуы, Кызыл Армиянең искиткеч кызу темплар белән көчле һөҗүм алып баруы турында сүз бара.

— Фронт сорый,—дидек без һәм 1942 нче елда дәүләт алдындагы йөкләмәләрнең берсен дә 1943 нче елга калдырмадык. Дәүләткә ашлык, терлекчелек продуктлары тапшыруны срогыннан алда үтәдек. Кызыл Армиянең 25 еллыгын 1943 нче ел өчен оборона фондына 275 центнер ашлык һәм 24 центнер ит тапшыру белән каршыладык.

— Бөтен көчебез фронтка булсын, —дидек без һәм фронттагы ил батырларына дәһшәтле сугыш кораллары төзү өчен үзебезнең саклык акчаларыбызны бирдек. Сугышчыларны җылы киендерергә, чын күңелдән әзерләнгән бүләкләребезне аларга җиткерергә теләдек. Танклар колоннасы төзүгә 50.000 сум, самолетлар эскадрильясы төзүгә 20.000 сум средство тупладык. Бик күп җылы киемнәр җибәрдек. Бәйрәм бүләгенә 457 литр сөт, 4 баш сарык, бер тана һәм тавыклар тапшырдык.

— Сугышчыларның сәламәтлегенык булсын, яралanучылар тизрәк терелсеннәр,—дидек без һәм сугышчыларның сәламәтлеген саклау фондына 4 центнер ит, 2.500 литр сөт һәм күп кенә йомырка бирергә булдык. Хәзер бу продуктларны тапшыру дәвам итә.

Арча районы, «Орнашбаш» колхозчылары менә шулай үзләренең хезмәтләрен сөекле илебезнең батырларына яхшы сыйфатлы авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерүгә багышлыйлар.

**Ф. ӘХМЕТОВ,**
колхоз председателе.

## УЛЛАРЫМ ӨЧЕН ДӘ ЭШЛИМ

Мин биредә, фронттан бик ерак-та. Ләкин үземне һәрвакыт шунда, улларым янында кебек хис итәм. Миңа хәзер 73 яшь инде. Туган илемне саклау сугышларында катнашканым бар. Шуның өчен 4 улымны озатканда да:

—Ватанны саклау изге бурыч. Кыю һәм нык булыгыз. Гел изге ният белән йөрегез,—дип фатиха бирдем.

Сугыш вакытында үзем дә ныгаеп киттем кебек. Тыныч вакытта, картайдым инде дип, өйдәрәк ятуны карый идем. Ә хәзер тик торуны яратмыйм. Ферма терлекләренең сәламәтлеген күзәтәм. Аларны авырулардан саклау чараларын күрәм. Аннан калган буш вакытларымда, вак-төяк эшләрдә булса да, колхозга булышам. Сбруйлар, баулар әзерләү өчен сүс әзерләп бирдем. Яз көне сукага чыгарга да уйлыйм. Кай вакыт киленем минем янга килә дә:

—Кайт инде, әткәй, арыгансыңдыр, — ди.

—Юк, килен, балам, мин әйтәм, монда улларым өчен дә эшлим. Аларга фронтта җиңелрәк булсын дим.

**Л. ИХСАНОВ.**

## УҢЫШНЫҢ НИГЕЗЕ

Чәчүлек җир яхшылап эшкәрткәнне, тәрбияләгәнне ярата. Туфрагы җентекләп эшкәртелгән, ашланган җирдә иген яхшы уңа. Шуның өчен дә без бу эшкә аеруча нык әһәмият бирәбез. Чәчүлек җирләрне агротехника кагыйдәләре буенча тәрбияләргә тырышабыз. Узган көздә туңга сөрүне вакытында үткәрү өчен күп кенә көч куйдык. Кышның беренче көннәреннән башлап кар тотарга чыктык. Бу эшне күбрәк укучы балалар һәм хатын-кызлар башкардылар. Алар билгеләнгән көннәрдә көрәкләр күтәреп басуга китәләр. Щитлар җитешмәгән урыннарда карны канаулар ясап тоттык. 376 гектар мәйданда кар тотылырга тиеш иде. Хәзер 439 гектар мәйданда тотылды инде.

Басуга тирес чыгару да план белән алып барыла. Берничә колхозчы һәркөнне шушы эш белән шөгыльләнә. Алар тиресне басуда өемгә өеп баралар. Көл, кош тизәге, фекали җыюны һәрбер бригада үзе оештыра. Ашламалар өчен уңайлы, коры урыннар билгеләдек.

Төрле культуралар буенча чәчүлек орлыгыбыз җитәрлек. Аларның кондициясе яхшы. Тик солы белән вика орлыгы бераз дымлырак иде. Без аны һава яхшы көннәрдә җилләтәбез. Орлыклык ашлык салынган амбарлар коры, кар-буран үтәрлек түгел. Амбар каравылчылары юк.

Машиналарга һәм башка авыл хуҗалыгы инвентарьларына ремонт ясауның сыйфатына нык әһәмият бирәбез. Мин аларны төзәтү урыннарында бик еш булам. Ремонтчыларның дөрес эшләүләрен күзәтәм. 3 чәчү машинасы, 26 сабан, 10 культиватор, 40 тырма, 50 сука камыты ремонтланды инде. Тагын бер чәчү машинасын һәм 20 арба төзәтәсе бар әле. Аны шушы айда төгәлләргә булдык.

Без агротехника укуларын да көздән үк башладык. Анда 42 колхозчы катнаша. Аларның күбесе хатын-кызлар. Түгәрәккә йөрүчеләр авыл хуҗалыгы үсемлекләре һәм аларны тәрбияләү, төрле ашламалар турында, ашлыкны саклау һәм корткычларга каршы көрәш, азык, һәм орлык ашлыкларын киптерү, орлыкны чәчүгә әзерләү турында өйрәнделәр. Алдагы занятиеләрдә кыр культураларын корткычлардан саклау, техник культураларны чәчү, чәчү әйләнеше һәм бөртекле культураларны урып-җыю турында өйрәнү планлаштырылды. Һәрбер теманы практикага бәйләп алып барабыз. Машиналар һәм башка инвентарьлар белән эш итү юлларын практикада күрсәтүне колхозның тәҗрибәле картлы иптәш Галимҗанов алып бара.

**Г. ЮСУПОВ,**
колхозның агротехнигы.

## БЕЗНЕҢ РАПОРТ

Мин колхозның тимерчелегендә 7 нче ел эшлим. Узган ел колхозымнан аерылып торырга туры килде. Бер ай буенча, кулыма корал тотып, дошманнан Ленин шәһәрен саклауда катнаштым. Сәламәтлегем коралымны үземне алмаштыручы иптәшләргә бирергә мәҗбүр итте. Колхозга кайту белән тимерчелектә чүкечемне кулыма алдым. Героик Сталинградны саклауда катнашкан иптәш Сабиров миңа ярдәмгә килде. Хәзер без аның белән икәү фронтка ярдәм итүне дәвам итәбез.

Ватан сугышы шартларында икенче тапкыр хәрби язны каршылауга әзерлектә без үзебезне зур җаваплы итеп саныйбыз. Безнең алачыгыбыздагы мичтә күмер нык ялкынлана, чүкечләребез көчлерәк суга. Сабаннарны һәм чәчү машиналарын төзәтеп бетердек инде. Чана һәм арбаларны тимерләдек. Кызыл Армиягә дә өрьяңа арбалар ясап җибәрдек.

Хәзер яз һәм җәй көннәрендә, кыр эшенең иң кызу вакытларында да эштә тоткарлык булмасын өчен төрле запас частьлар ясау белән шөгыльләнәбез. Искеләрне төзәтәбез. Ремонт өчен кирәкле тимер һәм күмерне үзебез табарга тырышабыз. Машиналар һәм башка авыл хуҗалыгы коралларын төзәткәндә тимерчелектә бер вакытта да ут сүнмәде.

—Тимерне кызу чагында сугыйк,—дидек без. Һәм ул безгә Кызыл Армиянең 25 еллык бәйрәменә кадәр ремонтны төгәлләргә мөмкинлек бирде. Без үзебезнең сугышчан иптәшләребезгә:

— Без сездән еракта булсак та, сезнең белән бер сафта барабыз. Алдагы көннәрдә дә, бөек Ленин һәм Сталин шәһәрләренә яхшы сыйфатлы авыл хуҗалыгы продуктлары җитештереп җибәрү өчен фундамент әзерлибез,—дип рапорт бирәсе килә.

**С. ЯКОВЛЕВ,**
колхоз тимерчесе.

## Бригада әзер

1942 нче елның беренче көннәрендә мине бригадам илемне дошманнан сакларга озатты. Колхозчы иптәшләр:

—1937 нче елдан бирле бригадабызны гел алга илттең. Бригаданыгыңды, баеды. Хәзер шул байлыкны саклау өчен Ватаның сиңа корал тоттыра. Колхозда эшләгәндәгечә нык тор. Гел алга бар, — диделәр.

Мин бригадамны вакытлыча калдырып, батыр ленинградлылар сафына бастым. Ленин шәһәрен дошманнан саклауда катнаштым.

Хәзер мин тагын колхозда. Ләкин һаман да ленинградлылардан калышмыйм. Бригадам белән гел алга барам. Бригададагы эшчән егетләрнең күбесе әле фронтта булуга да карамастан, элеккечә яхшы эшлибез.

Хәзер без язгы эшләргә тулысынча әзер. 13 машина барысы да төзек хәлдә. Пастромка һәм сука камытлары өчен сүс һәм киндерләрне үзебез әзерләдек. Төрле баулар, дилбегәләр, йөгәннәрне үзебез иштек, үрдек. Ремонтта ике кешелек төзү бригадасы оештырылды. Биредә Галимҗанов һәм Хисамиев иптәшләр эшлиләр.

Агрочаралар үткәрүне агротехник иптәш Юсупов җитәкчелегендә алып бардык. Кар тоту һәм тирес чыгару, көл җыю эшләренең планы үтәлде инде. Хәзер кош тизәге җыюны дәвам итәбез.

Агроукуга күбрәк хатын-кызлар йөриләр. Алар сөрү, тырмалау һәм чәчү техникасын үзләштерәләр. Хәсәнова, Шәкурова, Фазылова иптәшләр сабан сөрергә өйрәнәләр. Иптәш Касимова машинист булырга әзерләнә. Атлар аерым колхозчыларга беркетелде. Без фронттагы сугышчан иптәшләребезне:

—Язгы чәчүне тиз һәм яхшы сыйфатлы итеп үткәрербез,—дип ышандыра алабыз.

**Х. ШАҺИЕВ,**
икенче бригада бригадиры.

## ХЕЗМӘТ ҖИҢҮ КИТЕРӘ

Немец-фашист юлбасарлар көтмәгәндә һөҗүм итеп, совет халкының каушап калуына, колхоз хуҗалыгының җимерелүенә исәп тотканнар иде. Алар исәпләрендә нык ялгыштылар. Кыенлыклар алдында каушап калу совет кешесенең гадәте түгел. Колхоз хуҗалыгының да нигезе нык. Ул тиз арада үзенең эшен фронт таләп иткәнчә үзгәртеп корды. Без, колхозчылар үзебезнең көчебезне фронтка багышладык.

Мин үзем җәен-кышын белмичә, тырышып эшлим. Яз һәм җәй көннәрендә машинада чәчү чәчәм, урак урам. Быел кыш ремонт һәм төзү эше белән шөгыльләнәм. Фермаларның абзарларын ремонтлауга, сбруйлар әзерләүгә, арбалар ясауга күп кенә хезмәтемне куйдым. Колхозда минем хезмәттәш иптәшләрем күп. Безнең хезмәтебез колхозны ныгыта. Авыр сугыш шартларында туган кыенлыкларны үтеп җиңүгә алып бара. Моны без героик Кызыл Армиябезнең көчле һөҗүме белән азат ителгән меңнәрчә авылларда, йөзләрчә шәһәрләрдә янадан Совет байрагы җилфердәвендә күрәбез.

**К. ГАЛИМҖАНОВ.**

# СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

## 25 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

25 нче февральдә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

24 нче февральдә безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 200 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 10 артиллерия һәм 5 миномет батареясының утын бастырдылар.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар һәм дошманның бер терәк пунктын алдылар. Сугыш кырында дошманның 100 дән артык үле гәүдәләре калды. 13 пулемет, күп винтовкалар һәм сугыш припаслары кулга төшерелде.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че берләшмә частьлары халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бу пунктлар өчен булган сугышларда дошманның 300 гә якын солдат һәм офицерлары кырып ташланды. Немецларның 5 танкысы, берничә орудиесе һәм пулеметлары юк ителде.

* * *

Краматорскаядан көньяк-көнбатыштарак Н-че часть немецларның ике рота пехотасын юк итте. Дошманның 30 солдаты плен алынды. Безнең икенче бер частебызның сугышчылары, гитлерчыларның контратакаларын кире кайтарган чакта, 400 гә якын немец солдатларын һәм офицерларын кырдылар, дошманның 3 танкысын сафтан чыгардылар. Танкка каршы ата торган 4 орудие, 3 миномет һәм батальонның медицина пунктына кулга төшерелде. Безнең очучылар дошман аэродромнарына берничә һөҗүм ясадылар һәм немецларның җирдә тора торган 7 самолетын юк иттеләр.

* * *

Харьковтан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүм алып бардылар һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бер участокта немецлар Н-че частька атака ясарга маташканнар иде. Безнең сугышчылар, контрудар ясап, дошманны аударып ташладылар һәм качарга мәҗбүр иттеләр. Сугыш кырында немецларның 100 дән артык үтерелгән һәм 300 гә якын яраланган солдатлары һәм офицерлары калды.

* * *

Краснодардан көнбатыштарак безнең частьлар, алга таба барып, Мингрельская станциясын чолгап алдылар. Дошман гарнизоны корал ташлаудан баш тартты. Совет гаскәрләре штурм ясап Мингрельскаяны алдылар һәм немецларның 101 нче җиңел пехота дивизиясенең анда булган ике батальонын кырып ташладылар. 8 орудие, 70 пулемет, берничә әйбер һәм азык складлары, бер сугыш припаслары склады кулга төшерелде. Немецлар гарнизонының калдыклары—барлыгы 200 кеше плен алынды. Мингрельскаядан көнбатыштарак хәрәкәт итүче гитлерчылар чолганып алынган гарнизонга ярдәм күрсәтергә маташканнар иде. Безнең подразделениеләрнең омтылышлы атакасы белән дошман алып ташланды.

Совет очучылары немецларның 4 транспорт самолетын бәреп төшерделәр.

* * *

Украинаның бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды, засададан торып, шоссе юлы буйлап үтеп баручы немецлар колоннасына һөҗүм иткән. Гитлерчылар паникага бирелеп, юлда 70 үле гәүдә калдырып качып киткәннәр. Партизаннар 5 пулемет, 60 винтовка, сугыш припаслары һәм азык төялгән 12 олау кулга төшергәннәр. Шул ук отрядның бер группа партизаннары халык яши торган бер пунктта немецларның 2 орудиесен, берничә винтовкасын һәм 500 патронын кулга төшергәннәр.

* * *

Белоруссия ССР ның Витебск өлкәсендә немец-фашист кабахәтләр эшләгән канлы җинаятьләр турында хәбәр алынды. Оккупантлар авылларны тоташтан талыйлар һәм совет халкын берсен дә калдырмый кыралар. Январь аенда гитлерчы палачлар Полоцк районында гына да гражданнар халкыннан 546 кешене газаплап һәм атып үтергәннәр. Атып үтерелгән кешеләр арасында Васильев дигән бер карт, Сосноц авылы колхозчысы Евдокия Стернева, колхозчы Иван Матюшенко һәм башкалар бар.

* * *

Франция патриотлары немец кол итүчеләргә каршы көрәшне көчәйтәләр. Лион якынында азат укчылар отряды немецларның автоколоннасына һөҗүм иткән. Патриотлар 13 гитлерчыны кырып ташлаганнар, зенит орудиеләләре приборлары һәм запас частьлары төялгән 6 автомашинаны яндырганнар. Реймс-Ретель тимер юлында азат укчылар немецларның корал һәм сугыш припаслары төялгән бер эшелонын һәлак итүне оештырганнар. Парижда немец офицерлары ашап утыра торган ресторанга бик көчле бомба ташлаганнар. 11 гитлерчы үтерелгән һәм яраланган.

# Верховный Баш Командующий иптәш Сталин приказы турында чит ил матбугаты

ЛОНДОН, 24 февраль. (ТАСС). Верховный Баш Командующий иптәш И. Сталинның Кызыл Армиянең 25 еллыгына чыгарган приказы Англия газеталарының игътибар үзәгендә тора. Газеталар үз хәбәрләренең заголовкаларында немецларның гаять зур югалтулары турындагы саннарны китерәләр. Рейтер агентлыгының хәрби күзәтүчесе, иптәш Сталин приказына аңлатма биреп, бу приказ ышанычлык һәм көч белән сугарылган, дип яза. Сталин, ди күзәтүче, Германия стратегиясенең йомшаклыгын мастерларча күрсәтә. Кызыл Армиянең уңышлары рус командованиесенең хәрәкәтчән тактикасының нәтиҗәсе булып тора, бу командование Германия армиясе командованиесенә карaганда яхшырак маневр ясый белү һәм сугышка сәләтлелек күрсәтте.

НЬЮ-ЙОРК, 24 февраль. (ТАСС). Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның Кызыл Армиянең 25 еллыгына чыгарган приказы АКШ та зур кызыксыну тудырды. Америка радиостанцияләре бу приказны бөтен илгә киң рәвештә таратырдылар. Газеталар приказны күренекле урыннарга һәм эре хәрефләр белән басып чыгаралар.

АКШ ның дәүләт секретаре урынбасары Уэллес, иптәш Сталин приказы уңае белән хәбәрчеләр тарафыннан бирелгән сорауларга җавап биреп, рус армияләренең приказда күрсәтелгән гүзәл җиңүләренә үзенең сокланганлыгын белдергән. Уэллес, АКШ ның барлык халкы да шулай сокланачагына үзенең ышанганлыгын белдергән.

# ТУНИСТА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 24 февраль. (ТАСС). Союзникларның Төньяк Африкадагы кораллы көчләре штабының белдерүендә әйтелгәнчә, Америка һәм Англия гаскәрләре, Кассериннан төньяк-көнбатыштагы районда булган өзлексез өч көнлек сугышлар нәтиҗәсендә, дошманның һөҗүмен туктатканнар, һәм ул чигенергә мәҗбүр ителгән. Союзникларның гаскәрләре бик күп пленныйлар һәм дошман тарафыннан калдырылган зур сандагы коралларны алганнар. Союзникларның истребительләре һәм бомбардировщиклары көн буена чигенүче дошман колонналарына атака ясаганнар.

Уссельтидән көнбатыштарак районда дошманның атакалары уңышлы рәвештә кире кайтарылган. 23 нче февральгә каршы төндә союзникларның бомбардировщиклары Бизертага атака ясаганнар.

# САРАҖОГЛЫНЫҢ ЧЫГЫШЫ

ӘНКАРӘ, 22 февраль. (ТАСС). Кичә Төркиядә халык йортлары төзелү еллыгын бәйрәм итү уңае белән халык йортында җыелыш булган. Җыелышта республика президенты Гыйсмәт Инөнү дә булган. Министрлар советы председателе Сараҗоглы үзенең речендә халык йортларының ролен һәм әһәмиятен Төркиянең Ататөрек тарафыннан нигезе салынган җәмәгать тормышында прогресска омтылыш барлыкны күрсәтеп үткәннән соң болай дигән:

— Инде тышкы политикага килсәк, хәзерге авыр заманда, бөтен дөнья буталчык хәлдә торганда, безнең хөкүмәтебез алып бара торган политиканы тулы уңыш белән төгәлләнгән дип санарга мөмкин. Төркия милләте хөкүмәтнең яшерен йөкләмәләре юклыкны һәм булырга да мөмкин түгеллекне белә. Хәер бездән андый йөкләмәләрне таләп итмәделәр дә.

Без барлык дәүләтләр белән нормаль, дуслык мөнәсәбәтләрендә булган кебек, безнең Германия белән мөнәсәбәтләребез дә дуслык һәм һөҗүм итешмәү турындагы договорга нигезләнгәннәр. Күптән түгел Германия хөкүмәте безгә 100 миллион марка кредит бирде. Бу кредитның шактый өлешенә без сугыш материаллары сатып алабыз.

Соңгы айларга кадәр Кушма Штатлар безгә Англия аркылы ярдәм итеп килделәр. Соңгы айда кабул ителгән карарлар буенча алар безгә коралларны бурычка яки арендага бирү турындагы закон нигезендә турыдан-туры булышлык күрсәтәләр һәм бу булышлыкны көннән-көн арттыра баралар. Мин безгә күрсәтелә торган ярдәм өчен монда Америка хөкүмәтенә рәхмәт белдерүне үземнең бурычым дип саныйм. (Кул чабулар).

Советлар Союзы белән безнең мөнәсәбәтләребез бик алдынгы договорлар белән билгеләнәләр. Сез беләсез, бу договорлар заманында без кичергән һәм безнең илләребез бергәләшеп үткән авыр көннәр турындагы истәлекне гәүдәләндерәләр. Ул вакыттагы авыр көннәрдән алып хәзерге вакытка кадәр бу ике ил арасындагы мөнәсәбәтләр алдынгы договорлар белән билгеләнгән кебек, без ышанабыз, киләчәктә дә шул ук договорлар безнең үзара мөнәсәбәтләребезнең яхшы булуын билгеләрләр.

Инде Бөек Британиягә килсәк, бу держава — безнең союзнигыбыз һәм союз турындагы договор буенча аның тарафыннан китерелергә тиеш булган кораллар Төркиягә килүләрендә дәвам итәләр. Күптән түгел бу илнең баш министры, кунак сыйфатында, Аданага килеп китте һәм милләтебезнең юлбашчысы белән һәм безнең белән һәр ике ил өчен бик файдалы булган сөйләшүләр алып барды. Бу сөйләшүләр вакытында түбәндәге нәтиҗәләргә ирешелде:

1. Һәр ике ил бер-берләренә тулысынча ышаналар.

2. Англия һәм бөтен дөнья интересларын күздә тотып, Төркиянең яхшы коралланган һәм көчле булуы кирәк.

3. Бөек Британия Төркияне ашыгыч рәвештә коралландыра.

Һәр ике ил өчен күңелле һәм файдалы булып, Төркия өчен бигрәк тә күңелле һәм файдалы булган бу визит турындагы истәлекне Төркия халкы мәңге саклар.

Речененең ахырында Сараҗоглы Төркиянең җәмәгать һәм техника өлкәләрендә һәм үзенең эчке һәм тышкы эшләрендә тизлек белән алга баруын әйткән.

# СССР Оборона Халык Комиссары урынбасары Советлар Союзы Маршалы иптәш Б. М. Шапошниковта кабул мәҗлесе

1943 нче елның 23 нче февралендә, Кызыл Армиянең һәм Хәрби-Диңгез флотының 25 еллыгы уңае белән, СССР Оборона Халык Комиссары урынбасары Советлар Союзы Маршалы иптәш Б. М. Шапошников Куйбышев шәһәрендә чит илләрнең СССР дагы илчелекләре һәм миссияләре каршындагы хәрби һәм хәрби-диңгез атташелары һәм аларның ярдәмчеләре өчен кабул мәҗлесе үткәрде.

Мәҗлестә хәрби һәм хәрби-диңгез атташелары һәм аларның ярдәмчеләре, шулай ук Чит Ил Эшләре Халык Комиссары урынбасары иптәш С. А. Лозовский, контр-адмирал М. М. Долинин һәм Оборона, Хәрби-Диңгез Флоты һәм Чит Ил Эшләре Халык комиссариатларының җаваплы сотрудниклары катнашты.

# *Фронтовиклар семьяларына ярдәм итәбез*

Безнең цехта эшләүчеләрнең күпчелеге фронтовик семьясы. Ул, я фронтовикның анасы, я хатыны, я сеңлесе. Цех профсоюз оешмасы фронтовик семьяларының ничек торулары белән бертуктаусыз кызыксынып тора һәм аларга мөмкин булган кадәр материаль ярдәм күрсәтә.

Менә, бездә эшләүче иптәш Романованы алыйк. Аның иптәше Кызыл Армия сафында хезмәт итә. Иптәш Романованың 4 баласы бар. Цех профсоюз оешмасы быел иптәш Романовага утын китертеп бирде. Үзенә сырган телогрейка, киез итек, балаларына киез итекләр, мех буркилар, пальто алып бирде. Эчке белье, мендәр тышлары, простыняләр һәм мануфактура алу өчен ордерлар бирде.

4 нче мастерскойда эшләүче фронтовик хатыны иптәш Аникеевага 200 сум кайтарылмый торган пособия бирелде. Утын китертелде. Баласына пальто, мех бурки, киез итек алып бирелде. Шулай ук мануфактура, белье һәм башка әйберләр алу өчен ордерлар бирелде.

1 нче мастерскойда эшләүче иптәш Кузнецовага да цех профсоюз оешмасы зур ярдәм күрсәтте. Без аның балаларын балалар бакчасына урнаштырдык. Квартирасына утын китерттек. Үзенә һәм балаларына киез итекләр алып бирдек. Костюм, мануфактура алу өчен ордерлар бирдек.

Кызылармеец семьялары Жмурченко, Купорева, Эртман һәм башка иптәшләргә дә шушындый ук ярдәмнәр күрсәтелде.

Дөресен әйтергә кирәк. Без әле фронтовик семьяларының барысына да җитәрлек ярдәм күрсәттек дип әйтә алмыйбыз. Моңа кадәр мастерларның һәм участоклардагы профсоюз оештыручыларының бу эш белән җитәрлек шөгыльләнмәүләре нәтиҗәсендә, без кайбер иптәшләрнең бигрәк тә нинди ярдәмгә мохтаҗ булуларын үз вакытында ачыкландырып, аларга тиешле ярдәмне күрсәтә алмадык. Хәзер профсоюз оешмасы цехта эшләүче фронтовик семьяларының барысын да учетка алды һәм аларга киләчәктә дә һәрьяклап ярдәм күрсәтеләчәк.

Г. САБАЕВА,

Н-че заводның 6 нчы цех профсоюз оешмасы председателе.

Җаваплы редактор И. УЗБЕКОВ.

## Театрларда һәм киноларда

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. 28 нче февральдә иртә белән—„*Печән өстендәге эт*", кич—„*Хуҗа Насретдин*".

Татар дәүләт опера һәм балет театры. 27 нче февральдә — „*Травиата*".

Зур драма театры. Бүген һәм 27 нче февральдә—„*Нашествие*".

Дәүләт циркы. Бүген зур цирк тамашасы һәм французча көрәш ярышлары. Кич 8 сәгатьтә башлана.

Яшь тамашачылар театры. Бүген кичке 7 сәгатьтә — „*Москвичка*", 27 нче февральдә—„*Мәзәкчеләр*".

Татарстан дәүләт филармониясе. Бүген Татар дәүләт академия театры бинасында зур *эстрада концерты.* Кич 8 сәгать 30 минутта башлана.

„Электро" — „*Җиңелмәслекләр*".

„Унион"—„*Тажикстан улы*".

„Пионер" көндез һәм кич „*Райком секретаре*".

„Чаткы"—„*Антоша Рыбкин*".

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретарь, промышленность - транспорт һәм авыл хуҗалыгы бүлеге— АТС 79—29. типография 36—60.

ПФ1059 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФ ИЯСЕ № Заказ 298